ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 517-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

---

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 517-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2289-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрен яңадан бүлү турында

1 статья. **Әлеге Законны җайга салу предметы**

Әлеге Закон Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $8^2$ статьясы, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының $1^2$ өлеше, «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы җирлекләренең, муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары) шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүлә.

2 статья. **Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирлекнең җирле үзидарә органнарының түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:

1) генераль план проектын әзерләү турында карар кабул итү, шулай ук генераль планга үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул итү;

2) генераль план проектын әзерләү, генераль планны раслау, шул исәптән генераль планга үзгәрешләр кертү;

3) территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документын әзерләү һәм раслау, шул исәптән мондый бердәм документка үзгәрешләр кертү;

4) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар кабул итү, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү турында яки җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне кире кагу турында карар кабул итү;

5) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү;

6) шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

7) җир участогын яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турында яки мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

8) рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү яки мондый рөхсәт бирүдән баш тартуга турында карар кабул итү;

9) территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү турында карар кабул итү;

10) территорияне планлаштыру буенча документация әзерләүне тәэмин итү, территорияне планлаштыру буенча документацияне раслау, шул исәптән территорияне планлаштыру буенча документациягә үзгәрешләр кертү;

11) җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә төзелешкә рөхсәт бирү, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү;

12) җир участогының шәһәр төзелеше планын әзерләү, теркәү һәм бирү;

13) территорияне комплекслы үстерү турында карарны кабул итү һәм гамәлгә ашыру;

14) территорияне комплекслы үстерү турында җир кишәрлекләренең һәм (яки) аларда урнашкан күчемсез милек объектларының хокук ияләре инициативасы буенча гамәлгә ашырыла торган килешүләр төзү.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә муниципаль районның җирле үзидарә органнарының түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:

1) муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасын әзерләү турында карар кабул итү, шулай ук мондый схемага үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул итү;

2) муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасы проектын әзерләү, муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасын раслау, шул исәптән мондый схемага үзгәрешләр кертү;

3) шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

4) территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү турында карар кабул итү;

5) территорияне планлаштыру буенча документация әзерләүне тәэмин итү, территорияне планлаштыру буенча документацияне раслау, шул исәптән территорияне планлаштыру буенча документациягә үзгәрешләр кертү;

6) Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү дәүләт мәгълүмат системасы вәкаләтләрен әлеге өлешкә ярашлы рәвештә яңадан бүленә торган чикләрендә алып бару һәм мондый дәүләт мәгълүмат системасының мәгълүматларын, документларын һәм материалларын бирү.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә шәһәр округының җирле үзидарә органнарының түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:

1) генераль план проектын әзерләү турында карар кабул итү, шулай ук генераль планга үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул итү;

2) генераль план проектын әзерләү, генераль планны раслау, шул исәптән генераль планга үзгәрешләр кертү;

3) территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документын әзерләү һәм раслау, шул исәптән мондый бердәм документка үзгәрешләр кертү;

4) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар кабул итү, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү турында яки җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне кире кагу турында карар кабул итү;

5) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү;

6) шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

7) җир участогын яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турында яки мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

8) рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү яки мондый рөхсәт бирүдән баш тартуга турында карар кабул итү;

9) территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү турында карар кабул итү;

10) территорияне планлаштыру буенча документация әзерләүне тәэмин итү, территорияне планлаштыру буенча документацияне раслау, шул исәптән территорияне планлаштыру буенча документациягә үзгәрешләр кертү;

11) шәһәр округы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә төзелешкә рөхсәт бирү, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү;

12) җир участогының шәһәр төзелеше планын әзерләү, теркәү һәм бирү;

13) территорияне комплекслы үстерү турында карарны кабул итү һәм гамәлгә ашыру;

14) территорияне комплекслы үстерү турында җир кишәрлекләренең һәм (яки) аларда урнашкан күчемсез милек объектларының хокук ияләре инициативасы буенча гамәлгә ашырыла торган килешүләр төзү.

15) Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү дәүләт мәгълүмат системасы вәкаләтләрен әлеге өлешкә ярашлы рәвештә яңадан бүленә торган чикләрдә алып бару һәм мондый дәүләт мәгълүмат системасының мәгълүматларын, документларын һәм материалларын бирү.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2, 3, 5, 7, 8, 10 пунктларында, 2 өлешендәге 5 пунктында һәм 3 өлешендәге 2, 3, 5, 7, 8, 10 пунктларында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча җәмәгать фикер алышулары һәм җәмәгать тыңлаулары вәкаләтләре Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге Закон белән яңадан бүленә торган җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

5. Авария хәлендә дип танылмаган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле һәм торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү мәсьәләсе буенча торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турында карар проектына кертелгән күпфатирлы йортларның милекчеләренең гомуми җыелышлары вәкаләтләре Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге Закон белән яңадан бүленә торган җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3 статья. **Җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре яңадан бүленә торган срок**

Җирле үзидарә органнарының әлеге Законның 2 статьясының 1 - 3 өлешләрендә күрсәтелгән вәкаләтләре чикләнмәгән вакытка яңадан бүленә.

4 статья. **Әлеге Закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү**

1. Әлеге Закон белән яңадан бүленә торган вәкаләтләр архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Закон белән яңадан бүленә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибе, яңадан бүленә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, шул исәптән җирле үзидарә органнары фикерен исәпкә алу максатларында, җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында үзара хезмәттәшлек тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Әлеге Закон белән яңадан бүленә торган вәкаләтләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан

Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әлеге Законның 2 статьясының 3 өлешеннән тыш.

2. Әлеге Законның 2 статьясының 3 өлеше 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Аларны әзерләү турында яки аларга үзгәрешләр кертү турында карарлар әлеге Закон үз көченә кергәнче кабул ителгән, шулай ук аларга мөнәсәбәттә әлеге Закон үз көченә кергәнче Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган килештерү процедуралары башланган муниципаль районнарның территориаль планлаштыру схемалары, җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары, территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары, территорияләрне планлаштыру буенча документлар җирле үзидарә органнары тарафыннан әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган тәртиптә раслана.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда һәм шәһәр төзелеше документациясен әзерләү һәм раслау буенча нәтиҗәле эшне оештырганда республикада бердәм алымнарны тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасының күпчелек муниципаль берәмлекләренең шәһәр төзелеше документациясе эчтәлеге буенча искергән һәм форма буенча закон таләпләренә туры килми. Рөхсәт документларын бирү еш кына шәһәр төзелеше документларын һәм закон таләпләрен исәпкә алмыйча башкарыла, территорияләрне комплекслы үстерү механизмын кертү буенча җитәрлек чаралар күрелми, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын алып бару дөрес итеп һәм тулы күләмдә башкарылмый.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $8^2$ маддәсе нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Россия Федерациясе субъектының җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләре алар арасында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы $1^2$ өлештә каралган тәртиптә яңадан бүленә ала.

Күрсәтелгән нормалар нигезендә шәһәр төзелеше өлкәсен алга таба нәтиҗәле үстерү максатларында закон проекты белән Татарстан Республикасы җирлекләренең, муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге 19 вәкаләтен вәкаләтле республика башкарма хакимият органына – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына яңадан бүлү тәкъдим ителә.

Россия Федерациясе субъектлары законнарын анализлау күрсәткәнчә, 2014 елның 27 маеннан башлап (күрсәтелгән датадан Россия Федерациясе субъектының җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү мөмкинлеге каралган) төрле өлкәләрдә вәкаләтләрне яңадан бүлү мөмкинлегеннән Россия Федерациясенең 65 субъекты файдаланган, алар тарафыннан 160ка якын закон кабул ителгән. 40ка якын төбәк шәһәр төзелеше өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында законнар кабул итте.

Яңадан бүленә торган вәкаләтләр арасында закон проекты территориаль планлаштыру документларын әзерләү турында карарлар кабул итүне, аларны әзерләү һәм раслауны, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү турында карарлар кабул итүне, аларны әзерләү һәм раслауны, төзелешкә рөхсәт бирүне, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтләр һәм, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарына бирелгән һәм алар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә башкарылачак җәмәгать фикер алышулары, җәмәгать тыңлаулары үткәрүдән тыш, башкаларны күздә тота. Шундый ук алым 16 төбәк законында да бар. Мәсәлән, Мәскәү, Калининград, Липецк, Орлов,

Әстерхан өлкәләрендә, Приморье, Хабаровск краенда, шулай ук Россия Федерациясенең башка субъектларында яңадан бүлеп бирелә торган вәкаләтләр исемлегеннән җәмәгать фикер алышуларын һәм ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү буенча вәкаләтләр чыгарылган.

Җирле үзидарә органнарының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге закон проектында күрсәтелмәгән башка вәкаләтләрен тапшыру максатка ярашлы түгел, чөнки аларның үтәлеше нәтиҗәсе әзерләнгән һәм расланган территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларының сыйфатына, территорияне планлаштыру буенча документациягә, шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларына, шулай ук бирелгән рөхсәт документациясенә бәйле.

Вәкаләтләрне республика дәрәҗәсенә тапшыру Татарстан Республикасы территориясендә территориаль планлаштыру, шәһәр төзелеше зоналаштыру һәм төзелешне гамәлгә ашырганда бердәм сәясәтне гамәлгә ашырырга, шулай ук шәһәр төзелеше документларын вакытында һәм сыйфатлы актуальләштерергә мөмкинлек бирәчәк. Үз чиратында, төп шәһәр төзелеше документациясен әзерләү һәм раслау һәм рөхсәт документациясен бирү буенча республика дәрәҗәсендә нәтиҗәле башкарылган эш муниципаль дәрәҗәдә калган вәкаләтләрне тиешенчә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк һәм тормыш шартлары һәм халыкка күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатына тәэсир итмәячәк.

Шул ук вакытта закон проекты яңадан бүлеп бирелә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары фикерен исәпкә алуны күздә тота. Мондый исәпкә алу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә тәэмин ителергә тиеш.

Закон проекты белән вәкаләтләр чикләнмәгән вакытка яңадан бүленә, ә тиешле закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләү күздә тотыла Шул ук вакытта Казан һәм Чаллы шәһәрләренә карата закон нигезләмәләре 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәчәк.

Законны кабул итү шәһәр төзелеше эшчәнлеген оптимальләштерүгә ярдәм итәчәк, шулай ук шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында җирле үзидарә органнарына ярдәм күрсәтәчәк, Татарстан Республикасы территориясен үстерүнең гомуми планын исәпкә алып, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда аларның гамәлләрен координацияләүне тәэмин итәчәк, гомумән, Татарстан Республикасы буенча эшләнә һәм раслана торган шәһәр төзелеше документларының сыйфатын күтәрәчәк, бу исә уңайлы мохит тудыруга һәм гражданнарның яшәү шартларын яхшыртуга уңай йогынты ясаячак.

**«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү түбәндәгеләргә үзгәрешләр кертүне таләп итә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасын раслау турында» 2011 елның 24 сентябрендәге ПУ-585 номерлы Указларына;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карарына.

Моннан тыш, ««Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан яңадан бүлеп бирелә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен һәм яңадан бүлеп бирелә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында үзара хезмәттәшлекне билгеләүне таләп итәчәк.

**«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы законы белән кабаттан бүлеп бирелә торган вәкаләтләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанс чыгымнарын таләп итәчәк.

Яңадан бүлеп бирелә торган вәкаләтләрне Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт сәясәтен алып бару һәм архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, Татарстан Республикасында торак һәм коммуналь хуҗалык өлкәсендә идарә итү функцияләрен башкаручы вәкаләтле органы – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) башкарачак.

Бу Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә Министрлыкның территориаль органнарын булдыруны (67 берәмлек), Министрлыкта өстәмә структур бүлекчәләр булдыруны (17 берәмлек), Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының штат санын арттыруны (4 берәмлек) таләп итәчәк.

Финанслауның гомуми лимиты 54 684 929, 06 сум тәшкил итәчәк, шулардан 33 483 900,0 сум җирле бюджетлардан финанслау лимитларын тапшыру, Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә ихтыяҗ, бюджетара җайга салуны исәпкә алып, 21 201 029, 06 сум тәшкил итәчәк.